**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**дүртенче чакырылыш унөченче утырыш**

**10 март 2022 ел** **№ 48** **Айдар авылы**

**Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2018 елның 19нчы сентябре № 103 «"Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2021 елның 15нче ноябрендәге № 34 номерлы «Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2018 елның 19нчы сентябре № 103 «"Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2018 елның 19нчы сентябре № 103 «"Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

"Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәдә:

2.1. 12 статьяның 3 абзацын ", 12 статьяның 9 абзацында билгеләнгән очраклардан тыш," сүзләре белән тулыландырырга;

2.2. 12 статьяны түбәндәге эчтәлекле 9 абзац белән тулыландырырга:

"Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, шәһәр округының генераль планы территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин."

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хаҗиев

СОВЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ